# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Утар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

11.11.2024 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 28 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2024 елның 11 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Утар торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Түбән Утар торак пунктында җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау - грунт эшкәртү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, эшләр өчен килешү буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 143 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 73 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 73 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Утар торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.
2. «2025 нче елда Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Түбән Утар торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә дигән сорау буенча:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Түбән Утар торак пунктында җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау - грунт эшкәртү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, эшләр өчен килешү буенча түләү) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/korsabash адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Курсабаш авыл җирлеге башлыгы

А.Р. Гыймадиев